**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

19.09.2018 929-п

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында урнашкан Ромашкино Район нефть идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АЖ филиалы) «Михайловка – 1» ППС су алу корылмасының санитар саклык зонасы проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Су кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган су һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү өчен кулланыла торган су объектларының санитар саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 елның 29 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга 2018 елның 11 гыйнварындагы ТАТ ЧСТ 01886 ВЭ лицензияне һәм Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2015 елның 21 октябрендәге дәүләт санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килү турында № 16.11.11.000.Т.001996.10.15 санитар-эпидемиологик бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында урнашкан Ромашкино Район нефть идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АЖ филиалы) «Михайловка – 1» ППС су алу корылмасының санитар саклык зонасы проекты нигезендә **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында урнашкан Ромашкино Район нефть идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АЖ филиалы) «Михайловка – 1» ППС су алу корылмасының санитар саклык зонасы проектын (алга таба – Проект) расларга.

2. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында урнашкан Ромашкино Район нефть идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АЖ филиалы) «Михайловка – 1» ППС су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрен билгеләргә.

3. 2 нче кушымта нигезендә әлеге су алу корылмасының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимын билгеләргә.

4. Проект күчермәсен Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәгеләр буенча чаралар уздыруны тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында урнашкан Ромашкино Район нефть идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АҖ филиалы) «Михайловка – 1» ППС су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләре, бу чикләрдә территориядән файдалану кагыйдәләре һәм режимы турында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

территорияләр үсешенең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналарга бүлү схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә Проектны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
19.09.2018 № 929-п
боерыгына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында урнашкан Ромашкино Район нефть идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АҖ филиалы) «Михайловка – 1» ППС су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләре**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында урнашкан Ромашкино Район нефть идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АҖ филиалы) «Михайловка – 1» ППС су алу корылмасы аша эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү җир астындагы 1М, 2 М, 3 М номерлы өч скважина аркылы башкарыла. №1М һәм №2М су җыю скважиналары арасындагы ераклык – 10 метр.

Су алу корылмасы Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районында, Чистай шәһәреннән көньяк-көнчыгышка таба 20 км ераклыкта урнашкан.

Су алу скважиналарының географик координатлары:

№1М скв.: төньяк киңлектә 55°11'22,1", көнчыгыш озынлыкта 50°52'19,4";

№2М скв.: төньяк киңлектә 55°11'21,9", көнчыгыш озынлыкта 50°52'18,9";

№3М скв.: төньяк киңлектә 55°11'20,6", көнчыгыш озынлыкта 50°52'13,6".

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык сугүткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы.

Су алу участогының геологик кисеменнән һәм гидрогеологик шартларыннан чыгып, санитар саклык зонасының I пояс чикләре һәр су алу скважинасыннан 30 метрлы радиус белән билгеләнә. №1М һәм №2М скважиналар арасындагы аралык 10 метр тәшкил иткәнлектән, бу скважиналарның I поясының гомуми чикләре 70х60 метр тәшкил итәчәк.

Санитар саклык зонасының II поясы

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында Ромашкино РНУ («Транснефть-Прикамье» АҖ филиалы) «Михайловка – 1» ППС су алу корылмасының санитар саклык зонасының II пояс чикләре I пояс чикләре белән кушылган.

Санитар саклык зонасының III поясы

Әлеге су алу корылмасының санитар саклык зонасының III пояс чикләре һәр су алу скважинасыннан 124 метрлы радиус белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы Экология
һәм табигать ресурслары
министрлыгының 19.09.2018
№929-п боерыгына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында урнашкан Ромашкино Район нефть идарәсенең («Транснефть-Прикамье» АҖ филиалы) «Михайловка – 1» ППС су алу корылмасының санитар саклык зонасы чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

## 1. Санитар саклык зоналарының беренче поясы

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш бналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар саклык зонасының беренче поясы территориясендәге бинaлар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар саклык зонасындагы беренче поястан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.